ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

_______________          с. Верхний Услон          _______________

543

«Югары Ослан муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерлык җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларның (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына каралган вазифалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел №394 карары белән расланган «Авыл җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең һәм «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге»МКУ бухгалтерияләренең хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Башкарма комитетның 28.10.2020 ел №1002, 25.10.2022 ел №1269, 10.01.2023 ел №20 карарлары редакциясендә)

Югары Ослан муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, баш бухгалтерларның һәм бухгалтерларның (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Югары Ослан муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерлык җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларның (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына каралган вазифалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 23.04.2019 ел №394 карары белән расланган «Авыл җирлекләренең

үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең һәм «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге»МКУ бухгалтерияләренең хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы  Нигезләмәнең 3 нче пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Авыл җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ һәм «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге»  МКУ җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге өчен | Муниципаль казна учреждениесенең структур бүлекчәсе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 29500 | |
| Структур бүлекчә җитәкчесе (баш хисапчы) | | 29500 |
| Бүлек башлыгы | 25700 | 25700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 23300 | 23300 |
| Хисапчы | 22000 | 22000 |

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы М. М. Черменский

Әзерләде һәм бастырды
Е. Е. Колесова-4 нөсхәдә